Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

«27» октябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- ПУМ-4853 өчен бульдозер җайланмасы сатып алу (Беларус 82.1 тракторы базасында)

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару);

- һәйкәлне күчерү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү

- Фома авылында урамнарны яктырту җайланмасы;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Фома торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы карап тоту).»

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х. Абдрахманов

Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов